ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.09.2019 г. Заинск № 472

**"Мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга социаль яклау чаралары күрсәтү турында" Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елнын 20 сентябрендә кабул ителгән карарына үзгәрешләр кертү турында"**

"Мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә йөрүче балалары булган гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү, шулай ук фәкыйрьлек белән көрәш буенча чараларны гамәлгә ашыру йөзеннән, Зәй муниципаль районы Уставына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. "Мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга социаль яклау чаралары күрсәтү турында" (Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башкарма комитетының 157нче (27.01.2014), 253нче (10.02.2014), 1792нче (12.10.2015), 777нче (26.04.2016), 466нчы (21.03.2017), 73нче (24.01.2018) карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) Башкарма комитетның 2013 елнын 20 сентябрендә кабул ителгән 2078нче карары белән расланган мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре Тәртибенә "Мәктәпкәчә яшьтәгеләргә белем һәм тәрбия бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыручы балалар бакчаларында баланы караган һәм тәрбия биргән өчен әти-әниләр түләвендә гражданнарның рөхсәт ителгән

максималь өлеше” таблицасын түбәндәге эчтәлектәге юл белән тулыландырып, үзгәреш кертергә.

| | | | |
|---|---|---|---|
| яшәү минимумыннан түбән<br>(күпбалалы гаилә өчен) | 0 | 0 | 0 |

2. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырырга һәм муниципаль районның рәсми сайтына урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешенә күзәтчелек итүне Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А. В. Чапковка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**